КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 июль г.Казань № 565

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 4 октябрь, 714 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 4 октябрь, 714 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 4 октябрь, 755 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары В.Г.Шәйхразыевка йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Фәнни-тикшерену һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның тугызынчы абзацында «, шулай ук өченче ел укучы аспирант» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Грант бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак Вәкаләтле вәкилгә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт программасы нигезендә әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатларга бүлеп бирелә торган акча чикләрендә ун Гранттан һәрберсенең күләме 100 000 (йөз мең) сум тәшкил итә.»;

1.7 пунктта «президиум» сүзен «президент» сүзенә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Конкурска монография, уку әсбаплары, мәкаләләр (Россиянең фәнни цитаталау индексы базасына керә торган басмаларда кимендә биш мәкалә) циклы, методикалар һәм технологияләр эшләү яки булдыру буенча материаллар, яңа фәнни-техник продукция рәвешендә башкарыла торган һәм татар телендә язылган фәнни проектлар (алга таба – Проект) тәкъдим ителә.»;

3.2 пунктта:

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык.»;

3.3 пунктта «ике нөсхә» сүзләрен «бер нөсхә» сүзләренә алмаштырырга, «фәнни-оештыру бүлеге» сүзләрен «гуманитар фәннәр буенча хезмәттәшлекне координацияләү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 пунктның «г» пунктчасында «әлеге Нигезләмә» сүзләрен өстәргә;

3.11 пунктта «фәнни-оештыру бүлеге» сүзләрен «гуманитар фәннәр буенча хезмәттәшлекне координацияләү бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Грантларга лаек проектлар биш ел дәвамында Вәкаләтле учреждениенең гуманитар фәннәр буенча хезмәттәшлеген координацияләү бүлегендә саклана, алга

таба документларны саклау кагыйдәләре нигезендә Вәкаләтле учреждение архивына тапшырыла.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 – 3 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татар телендә фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлек алып баручы (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен максатчан грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 16 июль, 565 нче карары редакциясендә)

Форма

Татар телендә фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлек алып баручы
(югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча)
галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен
максатчан грантлар алу конкурсында катнашуга
заявка

1. Заявка бирүче эшли торган оешма (тулы һәм кыскартылган исемен, юридик затның адресын күрсәтергә):
________________________________________________________________________

2. Оешма җитәкчесе:
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда):
________________________________________________________________________
вазыйфасы: ____________________________________________________________
эш телефоны:
3. Заявка бирүче:
фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда): ________________
туган көне: ____________________________________________________________
вазыйфасы: ____________________________________________________________
телефоны:______________________________________________________________
e-mail: ________________________________________________________________
4. Проект турында мәгълүмат
исеме: ________________________________________________________________
юнәлеше*:_____________________________________________________________

---

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 ел, 4 октябрь, 714 нче карары белән расланган Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекне (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) татар телендә гамәлгә ашыручы галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен грантлар бирү турындагы нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгәннәрдән.

5. Проектның кыскача тасвирламасы (проектның төп бүлекләре эчтәлеген кыскача бәян итү):

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

6. Оешманың түләү реквизитлары:
банк исеме, ИНН, КПП: ____________________________________________
исәп-хисап счеты: ________________________________________________
корреспондент счеты: _____________________________________________
БИК:_____________________________________________________________

Әлеге заявкада тәкъдим ителгән барлык мәгълүмат, шулай ук өстәмә материаллар ышанычлы һәм дөрес, һәм вәкаләтле учреждениегә эш урыны буенча һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарында әлеге белешмәләрне төгәлләштерүче мәгълүматны соратырга ризалык бирәм, дип белдерәм.

Заявка бирүче: __________/ _____________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Заявкада һәм аңа теркәлә торган документлардагы шәхси мәгълүматларымны «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалыгымны белдерәм.

Заявка бирүче: __________/ _____________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Заявка бирүченең имзасын раслыйм:

| ______________________________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (заявка бирүче эшли торган оешманың кадрлар бүлекчәсе хезмәткәре яки башка вәкаләтле заты вазыйфасы) | (имзасы) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)) |

М.У.

Татар телендә фәнни-тикшеренү
һәм педагогик эшчәнлек алып
баручы (югары һәм урта һөнәри
белем бирү программалары буенча)
галимнәргә һәм укытучыларга
ярдәм күрсәтү өчен максатчан
грантлар бирү турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 16 июль, 565 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татар телендә фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлек алып баручы (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен максатчан грантлар алу конкурсында катнашу проектының (иң күбе биш бит) тасвирламасы

2. Проектны гамәлгә ашыра башлаган вакыттагы хәлгә карата гомуми тасвирнамә (иң күбе бер бит):

___

___

2. Проектның максатлары һәм бурычлары:

___

___

3. Чаралар планы (проектның төп чаралары тасвирнамәсе, этаплары һәм сроклары):

| Т/с | Гамәлгә ашыру этабы | Чаралар исеме | Гамәлгә ашыру сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

4. Проектның әһәмиятен һәм актуальлеген нигезләү:

___

___

5. Проект бюджеты (фаразлана торган кертемнәр һәм планлаштырыла торган чыгымнар сметасы, анның нигезләмәсе):

(сум)

| Т/с | Чыгымнар исеме | Үз акчасы | Сорала торган акча | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| Барысы бергә | | | | |

Чыгымнарның гомуми суммасы (сум):____________________________________

6. Проектны гамәлгә ашыр нәтиҗәлелеге күрсәткечләре:

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече | Күрсәткечнең зурлыгы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Кушымталар электрон (USB-флеш-тупланма) һәм басма (видеоматериаллар, фотографияләр, басма продукция) төрләрдә тапшырыла.

Заявка бирүче: __________/ ________________________________________________

(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

Татар телендә фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлек алып баручы (югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча) галимнәргә һәм укытучыларга ярдәм күрсәтү өчен максатчан грантлар бирү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 16 июль, 565 нче карары редакциясендә)

Конкурста катнашучыларның заявкаларын бәяләү критерийлары

Баллар саны заявканы бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә.

| Т/с | Критерийлар | Бәяләү, балл |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Проектны гамәлгә ашыруга планлаштырыла торган чыгымнарның һәм аннан көтелә торган нәтиҗәләренең нисбәте | планлаштырыла торган чыгымнар проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрдән артып китә – 0 балл;<br>планлаштырыла торган чыгымнар проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрдән артмый – 10 балл |
| 2. | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килүе | проектта проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге бирелә, күрсәткечләр проект бурычларына туры килми яки проектта күрсәткечләрнең исемлеге бирелми – 0 балл;<br>проектта проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге бирелә, күрсәткечләр проект бурычларына өлешчә туры килә – 5 балл;<br>проектта проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге бирелә, күрсәткечләр проект бурычларына туры килә – 10 балл |
| 3. | Планлаштырыла торган чараларның проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килүе | планлаштырылган чаралар проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килми – 0 балл;<br>планлаштырылган чаралар проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә өлешчә туры килә – 5 балл;<br>планлаштырылган чаралар проектны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләргә туры килә – 10 балл |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4. | Проектның теоретик әһәмият дәрәҗәсе | теоретик тикшеренүләр өлкәсендә проектның әһәмияте түбән – 5 балл;<br>теоретик тикшеренүләр өлкәсендә проект мөһим булып тора – 7 балл;<br>теоретик тикшеренүләр өлкәсендә проектның әһәмияте югары – 10 балл |
| 5. | Проектның практик әһәмият дәрәҗәсе | проектта каралган чараларның яки чараны гамәлгә ашыру методикалары, ысуллары, формаларының практик әһәмияте түбән – 5 балл;<br>проектта каралган чаралар, чараларны гамәлгә ашыру методикалары, ысуллары, формалары галимнәрнең һәм (яисә) педагогларның фәнни тикшеренүләре, гамәли эшчәнлеге өчен кулланыла торган – 7 балл;<br>проектта каралган чараларның яки чараны гамәлгә ашыру методикалары, ысуллары, формаларының практик әһәмияте югары – 10 балл |
| 6. | Тикшеренүнең методологик базасын билгеләү төгәллеге, проекттан көтелә торган конкрет нәтиҗәләрне билгеләү | тикшеренүләрнең методологик базасы төгәл билгеләнмәгән, проекттан көтелә торган нәтиҗәләр төгәл билгеләнмәгән – 0 балл;<br>тикшеренүләрнең методологик базасы өлешчә билгеләнгән, проекттан көтелә торган нәтиҗәләр комплекслы итеп билгеләнмәгән – 5 балл;<br>тикшеренүләрнең методологик базасы төгәл билгеләнгән, проекттан көтелә торган нәтиҗәләр комплекслы итеп билгеләнгән – 10 балл |
| 7. | Заявка бирү вакытына грант алуга дәгъва итүченең фәнни-методик хезмәте (соңгы өч елда проект темасы буенча басылып чыккан эшләрнең саны һәм сыйфаты) | соңгы биш елда проект темасы буенча басылып чыккан фәнни эшләр булмау – 0 балл;<br>соңгы биш елда проект темасы буенча басылып чыккан иң күбе өч фәнни эш булу – 5 балл;<br>соңгы биш елда проект темасы буенча басылып чыккан кимендә дүрт фәнни эш булу – 10 балл |
| 8. | Тикшеренүнең тулылыгы һәм тирәнлеге: проектның эшләнеше, башкару алгоритмы | проектның эшләнеше, башкару алгоритмы түбән – 0 балл;<br>проектның эшләнеше, башкару алгоритмы тулы булмау – 5 балл;<br>проектның эшләнеше, башкару алгоритмы тулы – 10 балл |

___________________